ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ
**КАРАРЫ**

«Татарстан Республикасы дәүләт мөлкәтен хосусыйлаштыру турында» Татарстан Республикасы Законының 2 һәм $6^1$ статьяларына үзгәрешләр кертү хакында» 150-7 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутатлары М.Һ. Галиев, Р.Г. Хөсәенов тарафыннан кертелгән «Татарстан Республикасы дәүләт мөлкәтен хосусыйлаштыру турында» Татарстан Республикасы Законының 2 һәм $6^1$ статьяларына үзгәрешләр кертү хакында» 150-7 номерлы Татарстан Республикасы законы проектын беренче укылышта кабул итәргә.

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы Рәисе — Ф.Х. Мөхәммәтшин

Казан шәһәре
2026 елның 19 феврале
№ 556-VII ДС

Проект
Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы депутатлары
М.Һ. Галиев, Р.Г. Хөсәенов
тарафыннан кертелә

**«Татарстан Республикасы дәүләт мөлкәтен хосусыйлаштыру турында» Татарстан Республикасы Законының 2 һәм $6^1$ статьяларына үзгәрешләр кертү хакында»**

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗАКОНЫ

**1 статья**

«Татарстан Республикасы дәүләт мөлкәтен хосусыйлаштыру турында» 2004 елның 26 июлендәге 43-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2004, № 7 (I өлеш); 2007, № 8; 2009, № 6, № 9 – 10; 2011, № 4 (I өлеш), № 10 (I өлеш); 2012, № 3; 2014, № 1 – 2; 2015, № 4, № 10 (I өлеш); 2016, № 10; Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2019, № 49 (I өлеш); 2020, № 1 (I өлеш), № 94 (I өлеш); 2021, № 77 (I өлеш); 2023, № 27 (I өлеш), № 81 (I өлеш); 2024, № 34 (I өлеш), № 45 (I өлеш); 2025, № 49 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 2 статьяның $7^4$ пунктын үз көчен югалткан дип танырга;

2) $6^1$ статьяга түбәндәге эчтәлекле җөмлә өстәргә:
«Дәүләт мөлкәтен хосусыйлаштыруның фаразлау планына (программасына) кертелгән унитар предприятиеләрнең, акционер җәмгыятьләрнең һәм җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятьләрнең әлеге статьяда каралган арадаш бухгалтерлык (финанс) хисаплылыгы дәүләт мәгълүмат бухгалтерлык (финанс) хисаплылыгы ресурсын формалаштыру максатларында тапшырылырга тиеш түгел.».

**2 статья**

1. Әлеге Закон, әлеге Законның 1 статьясындагы 1 пунктыннан тыш, рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.
2. Әлеге Законның 1 статьясындагы 1 пункты 2026 елның 1 июленнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Рәисе

**«Татарстан Республикасы дәүләт мөлкәтен хосусыйлаштыру турында» Татарстан Республикасы Законының 2 һәм 6[1] статьяларына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законы проектына**

# АҢЛАТМА

«Татарстан Республикасы дәүләт мөлкәтен хосусыйлаштыру турында» Татарстан Республикасы Законының 2 һәм 6[1] статьяларына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законы проекты (алга таба – закон проекты) Татарстан Республикасы Законын федераль законнарга туры китерү максатларында эшләнде.

«Конкуренцияне яклау турында» Федераль законга һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» 2025 елның 29 декабрендәге 577-ФЗ номерлы Федераль закон белән берничә Россия Федерациясе закон актына аренда шартнамәләре, түләүсез файдалану шартнамәләре, мөлкәткә ышанычлы идарә итү шартнамәләре, дәүләт мөлкәтен яисә муниципаль мөлкәткә карата хуҗа булу һәм (яисә) аннан файдалану хокуклары күчүне күздә тоткан башка шартнәмаләр төзү хокукына торглар оештыруга һәм үткәрүгә гомуми таләпләрне билгеләүгә юнәлдерелгән үзгәрешләр кертелде. Алар нигезендә, Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән очракларда, шартнәмаләр төзү хокукына һәм (яисә) билгеле бер эшчәнлекне гамәлгә ашыру хокукына торглар аларны оештыруга һәм үткәрүгә 2026 елның 1 июленнән «Конкуренцияне яклау турында» 2006 елның 26 июлендәге 135-ФЗ номерлы Федераль законның 17[3] статьясында каралган гомуми таләпләрне исәпкә алып үткәреләчәк.

Шуңа бәйле рәвештә, закон проекты белән дәүләт мөлкәтен мөмкин булган минималь бәягә сату-алу шартнамәсен төзү тәртибен билгеләү буенча Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының вәкаләтен үз көчен югалткан дип тану күздә тотыла.

«Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2025 елның 15 декабрендәге 471-ФЗ номерлы Федераль закон белән дәүләт мөлкәтен һәм муниципаль мөлкәтне хосусыйлаштыруның фаразлау планнарына (программаларына) кертелгән унитар предприятиеләр, акционер җәмгыятьләр һәм җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятьләр дәүләт мәгълүмат бухгалтерлык (финанс) хисаплылыгы ресурсын формалаштыру максатларында арадаш бухгалтерлык (финанс) хисаплылыгын тапшырудан азат ителәләр.

Закон проекты белән охшаш үзгәрешне «Татарстан Республикасы дәүләт мөлкәтен хосусыйлаштыру турында» 2004 елның 26 июлендәге 43-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының дәүләт мөлкәтен хосусыйлаштыруның фаразлау планына кертелгән юридик затлар тарафыннан бухгалтерлык (финанс) хисаплылыгын тапшыру мәсьәләләрен регламентлаштыра торган 6[1] статьясына кертү тәкъдим ителә.

**«Татарстан Республикасы дәүләт мөлкәтен хосусыйлаштыру турында» Татарстан Республикасы Законының 2 һәм $6^1$ статьяларына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законын кабул итүгә бәйле рәвештә үз көчләрен югалтуы танылырга, туктатылып торырга, үзгәртелергә яисә кабул ителергә тиешле Татарстан Республикасы законнары һәм башка норматив хокукый актлары**

**ИСЕМЛЕГЕ**

«Татарстан Республикасы дәүләт мөлкәтен хосусыйлаштыру турында» Татарстан Республикасы Законының 2 һәм $6^1$ статьяларына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законын кабул итү Татарстан Республикасы законнарының үз көчләрен югалтуын тануны, аларны туктатып торуны, үзгәртүне яисә башкаларын кабул итүне таләп итми.

«Татарстан Республикасы дәүләт мөлкәтен хосусыйлаштыру турында» Татарстан Республикасы Законының 2 һәм $6^1$ статьяларына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законын кабул итү «Татарстан Республикасы дәүләт мөлкәтен мөмкин булган минималь бәягә сату-алу шартнамәсен төзү тәртибен раслау турында» 2024 елның 8 августындагы 634 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарын үз көчен югалткан дип тануны таләп итәчәк.

**«Татарстан Республикасы дәүләт мөлкәтен хосусыйлаштыру турында» Татарстан Республикасы Законының 2 һәм 6$^{1}$ статьяларына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законы проектын**

# ФИНАНС-ИКЪТИСАДЫЙ НИГЕЗЛӘҮ

«Татарстан Республикасы дәүләт мөлкәтен хосусыйлаштыру турында» Татарстан Республикасы Законының 2 һәм 6$^{1}$ статьяларына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законын кабул итү Татарстан Республикасы бюджеты акчалары исәбеннән каплана торган өстәмә чыгымнар таләп итми.